ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

01.08.2022 — 32

Юл билгеләрен урнаштыру турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Юл хәрәкәте иминлеге турында” 10.12.1995 ел 196-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 2007 елның 8 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законнар, “Татарстан Республикасында автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында” 03.08.2009 елның 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә юл хәрәкәте тәртибен һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү, урамнарда һәм юлларда юл хәрәкәтен оештыру максатыннан, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Октябрьский авыл җирлеге торак пунктларына кергәндә 9,5 тоннадан артык массасы булган "Йөк автомобильләре хәрәкәте тыелган" 3.4 тамгасын куерга.

2. Россия Эчке эшләр Министрлыгының "Югары Ослан" муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлегенә Октябрьский авыл җирлегенең күрсәтелгән автомобиль юлларында юл хәрәкәте кагыйдәләренең үтәлешен тикшереп торуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы — Ш. Р. Азизов